ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 август, 2021 ел № 8/10

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 2352 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге № 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8, 2020 елның 18 мартындагы 38/6 номерлы Карарлары редакциясендә), 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«13. Хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) тиешле чорда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль унитар предприятиеләр, шулай ук муниципаль милектә булган акционерлык җәмгыятьләре акцияләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларында өлешләр (күчемле мөлкәттән тыш) исемлеге керә. Хосусыйлаштыруның фараз планында (программасында) муниципаль милекнең характеристикасы, тиешле елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) нигезендә шәһәр бюджетына керемнәрнең фаразы һәм хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты күрсәтелә.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев